# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге составына керүче Тагашур авылы торак пунктында

07 ноябрь 2020 ел №6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35нче маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Тагашур авылында гражданнар җыены карар итте:

1. Балтач районы Чепья авыл җирлегенең Тагашур авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән; 50 процент күләмендә ташлама каралган 1 төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк өлкән пенсионерлардан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән тыш; 500 сум күләмендә үзара салым акчасы җыярга.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- коймалар белән спорт мәйданчыгын төзекләндерү, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру ;

- ял паркын планлаштыру һәм коймалау.

3. Җыен нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә. http://pravo.tatarstan.ru> Балтач муниципаль районы сайтында baltasi.tatar.ru к

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче

Чепья авыл җирлеге башлыгы А. Г. Нотфуллин